**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**СТАРОКАДЕЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ул.Советская, д.6, с.Старое Кадеево, 423117

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИСКЕ КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 6 йорт, Иске Кади авылы, 423117

тел./факс (84396) 3-13-25 email: Skad.Cmn2@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.01.2023 ел **Иске Кади авылы** **№ 1**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Иске Кади авыл җирлегендә җирләү буенча**
**хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә**
**күрсәтелә торган хезмәтләрнең**
**хакын раслау турында**

1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм күмү эше турында» 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пункты һәм 12 статьясындагы 3 пункты нигезендә (үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында «Күмү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» һәм 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы «Тарифлар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты мәсьәләләре» карарлары нигезендә күмү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе җирле үзидарә органнары белән Россия Федерациясе Пенсия фонды, Россия Федерациясе Социаль иминият фонды бүлекләре белән, шулай ук Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары белән (Тарифлар буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты – алга таба Дәүләт комитеты) килештерү буенча билгеләнә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Кади авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Кади авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә 7793,48 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Кади авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2022 елның 31 гыйнварындагы 2 номерлы карарының үз көчен югалтуын таныргa.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Иске Кади авыл җирлеге башкарма комитеты
җитәкчесе Н.В.Мөктәсимов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Кади авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 елның 31 гыйнварындагы
1 нче карарына

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе
2023 елның 1 февраленнән

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум.)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2838,18 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1295,72 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3659,58 |
| **Барлыгы** | **7793,48** |

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Кади авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 елның 31 гыйнварындагы
1 нче карарына

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе
2023 елның 1 февраленнән

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 297,29 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2540,89 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1295,72 |
| 5. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 3659,58 |
| **Барлыгы** | **7793,48** |